СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫНЫҢ ИҖТИМАГЫЙ СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | №95 (7268) | 8 август, 1991 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

## „Уңыш-91" пресс-группасы хәбәр итә

7 августка 39160 гектар бөртекле һәм бөртекле-кузаклы культуралар уңышы җыелды. Бу — барлык мәйданның дүрттән өче чамасы.

Арпа һәм солы культураларын суктыру тәгәлләнеп килә инде. Сабан бодаеның 3456 гектарыннан уңыш җыелды. Бу әлеге культура чәчүлекләренә карата 26,5 процент.

Уҗым культуралары чәчү өчен 21556 гектар җир хәзерләнде. Аның 551 гектарында орлык күмдерелде инде. Туңга сөрү 12062 гектарда башкарылды.

## *Кыр батырларына тигезләнегез!*

## Районның ашлык суктыруда иң әйбәт күрсәткечләргә ирешкән алдынгы комбайнчылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче—исем-фамилиясе, өченче — хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан суктырылган бөртек (центнерларда). (Мәгълүматлар 1991 елның 7 августына).

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Абрамов В. Д. | «Восход» | ДОН-1500 | 7800 |
| 2. | Кыямов Х. К. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 7317 |
| 3. | Донсков А. Е. | «Большевик» | ДОН-1500 | 7086 |
| 4. | Нилов Н. В. | Синдряков исем. | ДОН-1500 | 6100 |
| 5. | Сафин Ә. Ә. | Ульянов исем. | ДОН-1500 | 5928 |
| 6. | Хәсәнҗанов Н. Г. | «Чишмә» | СК-5 | 5100 |
| 7. | Абдрахманов Р. А. | «Игенче» | ДОН-1500 | 4903 |
| 8. | Ситдыйков С. Ш. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 4890 |
| 9. | Бикиев С. З. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 4800 |
| 10. | Казаков Ю. А. | «Заря» | ДОН-1500 | 4659 |
| 11. | Матвеев В. А. | «Алга» | СК-5 | 4512 |
| 12. | Абдуллин И. Ә. | «Рассвет» совхозы | ДОН-1500 | 4500 |
| 13. | Сөнгатуллин В. В. | «Таң» | СК-5 | 4500 |
| 14. | Ибраһимов Ә. И. | «Игенче» | ДОН-1500 | 4446 |
| 15. | Хәлимов М. Х. | «40 лет Победы» | ДОН-1500 | 4414 |
| 16. | Вафин Р. Р. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 4411 |
| 17. | Шәрәков Ф. Г. | «Алга» | СК-5 | 4310 |
| 18. | Закиров И. Г. | «Таң» | СК-5 | 4200 |
| 19. | Фәттахов Ф. Ф. | «Алга» | СК-5 | 4118 |
| 20. | Нуруллин Р. Ә. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 4113 |

## 1991 нче ел уңышын уру алдынгылары

Беренче багана—тоткан урыны, икенче—исем-фамилиясе, өченче—хуҗалыклар исеме, дүртенче—машина маркасы, бишенче—урып-җыю башыннан күпме урдырылган (гектарларда). Мәгълүматлар 7 августка.

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Шәфигуллин Р. З. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 735 |
| 2. | Алиев С. Х. | XXI партсъезд исем. | СК-5 | 591 |
| 3. | Әхсәнов С. З. | «Игенче» | СК-5 | 540 |
| 4. | Хәлиуллин В. Х. | «Таң» | СК-5 | 540 |
| 5. | Шәйдуллин И. Б. | «Комбайн» | СК-5 | 480 |
| 6. | Демьянов Е. М. | «Восход» | СК-5 | 471 |
| 7. | Зиннуров Ш. Р. | «Игенче» | СК-5 | 440 |
| 8. | Алексеев А. В. | «Сөлчә» совхозы | СК-5 | 435 |
| 9. | Миннеголов С. Х. | Муса Җәлил исем. | СК-5 | 420 |
| 10. | Родионов А. В. | Синдряков исем. | СК-5 | 410 |
| 11. | Бильданов Н. М. | «Чишмә» | СК-5 | 400 |
| 12. | Волков В. Я. | «Заря» | СК-5 | 393 |
| 13. | Максимов И. Ф. | «Москва» | СК-5 | 385 |
| 14. | Захаров В. А. | Синдряков исем. | СК-5 | 333 |
| 15. | Хәсәнов М. Р. | «Таң» | СК-5 | 310 |

## ДАН ФЛАГЫ КҮТӘРЕЛӘ

Район үзәгендә Дан флагы «Восход» колхозы комбайнчысы Василий Дмитриевич АБРАМОВ хөрмәтенә инде берничә тапкыр күтәрелде. Соңгы өчкөнлек нәтиҗәләре буенча Дан флагы кабат аның хөрмәтенә җилферди. Ул үзенең «ДОН-1500» комбайнында 7800 центнер ашлык суктырып, район комбайнчылары арасында әйдәп бара.



XXI партсъезд исемендәге колхозда Сәмигулла Шәрифуллович Ситдыйков егерме дүртенче елын комбайнчы булып эшли. Беренче мәртәбә кыр корабына утырган көннән башлап ул үзенең игенче һөнәренә бер генә мәртәбә дә хыянәт итмәде. Иң авыр вакытларда да ир-ат була белде, аның көчле куллары штурвалны ычкындырмады.

Бүгенге көндә Сәмигулла Шәрифуллович башка комбайнчылар белән берлектә 740 гектар мәйдандагы басуда бодай суктыра. Ул урак башланганнан бирле 5000 центнерга якын ашлык суктырды инде.

Рәсемдә: XXI партсъезд исемендәге колхоз комбайнчысы Сәмигулла Шәрифуллович Ситдыйков.

### БОДАЙГА ТӨШТЕЛӘР

«Правда» колхозында Николай Аркадьевич Алексашкин җитәкчелегендәге аренда звеносы арендачылары язгы кыр эшләре тәмамлангач ук, комбайннарын сыйфат белән ремонтлап, урак җиткәнне түземсезлек белән көткәннәр иде. Инде менә киеренке хезмәт чоры бара. Алар шушы көннәрдә 254 гектар мәйдан биләгән солыны суктырып бетереп, бодайны теземнәргә сала башладылар.

**И. ГРИГОРЬЕВ.**




## Казеин бәрабәренә... дефицит

Казеинның аксымга бай матдә икәнлеген, буяу, җилем һәм башка кирәкләр ясау өчен файдаланылуын Норлат сөт заводы эшчеләре быел аеруча нык аңладылар. Элек чималга предприятиедә кадер юк иде, икенчел дәрәҗәдәге эш итеп кенә карадылар. Ә быел аертылган сөтнең һәр килограммын әлеге төр продукция җитештерүгә тоту өчен тырышалар.

Әлеге төр продукциягә мондый караш дәүләт заказыннан тыш казеинны чит илгә озата башлагач туды. Заводның планнан тыш продукциясен совет—һинд катнаш предприятиесе сатып ала башлады. Ул аны читкә чыгара, валютага сата. Валютаның 50 проценты завод исәбенә күчерелә.

Чит ил акчасы булганда исә теләсә ни алып була. Внешэкономторг аркылы завод эшчеләренә АКШта эшләнгән курткалар, башка илләрдән кертелгән көзге мех аяк киемнәре, туфлиләр, пальтолар кайтарттык. Дистәдән артык гарнитурны да шул юл белән алдык. Дефицит товар безнең эшчегә совет акчасы белән дә арзан бәягә килә.

Казеин икенчел сорт чимал гына түгел хәзер. Завод аны планнан тыш мөмкин кадәр күбрәк җитештерү өчен тырыша. Беренче ярты елда чит илгә чыгару өчен 50 тонна әзерләгән идек. Икенче ярты еллыкта да сынатыр исәп юк: дәүләт заказын өченче кварталда башкарып, дүртенчесендә үз ихтыяҗларыбыз өчен эшләргә исәп. Бу безгә тагын байтак дефицит товар сатып алырга мөмкинлек бирәчәк.

**З. БИЛДАНОВ,**
Норлат сөт-май заводы директоры.

## *Бер колхоз хәбәрләре*

### Кышкы чорга әзерлек бара

**«1 нче Май» колхозы.** Терлекчелек биналарын кышкы чорга ремонтлауда ирле-хатынлы Валентина Яковлева һәм Александр Назаров, Николай Варламов, Геннадий Леонтьев, Александр Семенов зур тырышлык күрсәтәләр.

Алар сыерлар һәм бозаулар абзарларындагы искергән идәннәрне алыштыралар, чыгу-керү юлларына бетон җәяләр, улакларны төзәтәләр һәм башка төр эшләрне башкаралар.

Дүрт-биш кешедән торган бу бригада ремонт өчен кирәк булган материалларны урманга барып үзе әзерләде.

### Терлек азыгы мул булсын

Хуҗалыкта сенаж һәм силос әзерләү дәвам итә. Бүгенге көндә КСК-100 комбайнында Вячеслав Тимофеевич Попов 180 гектар мәйданда яшел масса урдыра. Ул ватылган очракта Т-150 тракторчысы Олег Владимирович Краснов КС-2,6 агрегаты белән ярдәмгә килә. Шулай итеп тоткарлыкка юл куелмый.

Шоферлардан исә терлек азыгын ташуда Николай Кузьмич Яковлев, Николай Анатольевич Семенов аеруча өлгерлек күрсәтәләр. ДТ-75 тракторы белән массаны тыгызлап торуда Сергей Павлович Короткин һәм К-701 тракторчысы Николай Миронович Иванов та сынатмыйлар.

Хуҗалыкның азык базына барлыгы 410 тонна сенаж салынды инде.

### Салам җыела

Саламны комплекслы җыюда Т-70 тракторына тагылган ВТУ-10 агрегатлары белән Владимир Кузьмич Яковлев, Юрий Семенович Марков шөгыльләнәләр. Алар зур тырышлык куеп эшлиләр һәм югалтуларга юл куймыйлар.

СШР-0,5 агрегатында МТЗ-80 тракторы белән Владимир Ильич Короткин да үз эшен зур җаваплылык хисе тоеп башкара. Кибәнне исә Зиновий Иванович Краснов, Нина Анисимовна Макарова, Юлия Ильинична Михеева тигезләп торалар.

Бүгенге көндә 903 гектар мәйданның саламы җыелды, 820 тоннасы эскерткә куелды.

### Норманы үти

Җирне туңга сөрүдә К-701 тракторчысы Клим Иванович Тихоновның эшенә тел-теш тидерерлек түгел. Ул үз нормасын 120—130 процентка арттырып үтәп бара. Хәзерге вакытта Клим Иванович 191 гектар мәйданда җир сөрде.

Эшне кыска вакытларда һәм югары темпта тәгәлләү өчен сөрүдә катнашучы башка тракторчылар да вакыт белән исәпләшмичә эшлиләр.

**Н. ГРИГОРЬЕВ,**
экономист.

## Почтальон алып килә,

почтальон гына белә, дип җырлыйлар иде. Чыннан да ул һәркемнең хәлен белә бит. Әнә безнең Төрнәс авылы хат ташучысы Галина Федотова авыл халкын сөендереп хатларны, газета-журналларны вакытында китереп җиткерә. Без, пенсионерларның һәр соравын, һәр үтенечен һичсүзсез башкарырга тырыша.

Аның намуслылыгы, кешеләргә карата игътибарлы булуы безне сөендерә. Аңа эшендә уңышлар, кеше хакына гел шулай тырышып эшләвен телисе килә.

**Сугыш һәм хезмәт ветераннары исеменнән: С. Ксенофонтов, В. Калинина һәм башкалар.**




## Бүләк соңлап тапшырылды

Редакциягә Кизләү сельпосында (хәзер ваклап сату сәүдә предприятиесе) озак еллар эшләп пенсиягә чыккан сугыш һәм хезмәт ветераннары Зиятдин Гыймалетдинов, Әхмәт Зиннуров, Фатыйх Ситдыйковтан хат килгән иде.

Хат авторлары Бөек Җиңү көнендә үзләренә игътибар булмау, колхозчы ветераннарның колхоз идарәсеннән бүләк алулары, ә үзләренең мәхрүм калулары турында язганнар иде.

«Әйбер кирәктән түгел, ә күңел төшүдән язабыз. Картайган саен кешенең күңеле нечкәрә икән, ихтирам итүне сорый»,—дип язалар алар.

Хат райпо идарәсе рәисе Һ. Х. Садыйковка юлланган иде. Аңардан түбәндәге җавап алынды.

«9 май бәйрәмендә сугыш ветераннарын бәйрәм белән котлап Норлат шәһәренең беренче ашханәсенә чәйгә чакырдык, шунда истәлек бүләкләре дә тапшырылды. Бирегә килә алмаган ветераннарга бүләкне тапшыру өчен РТП директорларына бирдек. Ә З. Гыймалетдинов, Ә. Зиннуров, Ф.Ситдыйков иптәшләргә бүләкне сатучы Зарипова тапшырды. Билгеле, соңга калып. Моның өчен гафу үтенәбез», диелгән анда.

### ЭШ ТӘМАМЛАНДЫ

Хуҗалыкның 198 гектарлы чөгендер басуын өченче кат эшкәртү тәмамланды. Тракторчылар Госман Зәйдуллин, Фәрит Хәсәншин, Исламгәрәй Сатдаров рәт араларын йомшартканнан соң, чөгендерче апалар участокларны чүп үләннән арындырдылар.

**Г. САДЫЙКОВА,**
Муса Җәлил исемендәге колхоз.

*• Район Советы сессиясендә*

# Бергәләп эшләргә

Халык депутатларының җирле Советлары, аларның башкарма комитетлары—урыннардагы дәүләт власте органнары. Аларның тырышлыгына районда производство һәм социаль мәсьәләләрне хәл итү программаларының үтәлеше күп бәйле.

Совет депутатлары исә бу бурычларны хәл итүдә инициатива күрсәтеп эшләргә тиешләр. Депутатлар башкарган эшләре, сайлаучылар наказларын үтәү буенча халык алдында отчет та тоталар. Бу закон нигезендә каралган. Бүген хокукый дәүләт турында сүз алып барганда, закон теге яки бу кешенең теләкләренә бәйсез рәвештә үтәлгәндә элеге форма аеруча мөһим. Сайлаучылар наказы депутат өчен эшчәнлеген оештыруның төп нигезе булып тора.

Минем 49 нчы сайлау округында 522 сайлаучы яши. Аларның күбесе ветераннар. Шуңа күрә алар депутатка ярдәм сорап башкалардан күбрәк мөрәҗәгать итәләр. Энгельс һәм Суворов урамнарының 15 нче һәм 19 нчы йортларында яшәүче Соловьев, Мещанов су колонкасының төзек түгеллегеннән зарланып килгәннәр иде. МПП начальнигы Ф. И. Гайнуллинга рәхмәт әйтергә кирәк, бу сигналга вакытында игътибар итте һәм кимчелек кыска срокта төзәтелде. Ә Калинин урамында яшәүче Сәлахов хуҗалыгын кышкы чорда грунт сулары баса. Бу мәсьәлә хәл итүне көтә. Ләкин шәһәр Советы аны һаман суза килә. Фрунзе урамында чүп-чарны җыю мәсьәләсе дә хәл итүне көтә.

Бер уңайдан шуны дә әйтеп үтәргә кирәк, депутат сайлаучылар алдында җаваплы икән, сайлаучылар үзләре дә, минемчә, депутат алдында җавап тотарга тиешләр. Моны шуның өчен әйтүем. Мәсәлән, Куйбышев урамы безне күрше авыллар, районнар белән тоташтыручы үзәк магистраль, әмма аны чүп үләне басып киткән. Монда шуны да истән чыгарырга ярамый, депутат шәхси йортлар каршындагы чүп үләнен чабып йөри алмый бит инде, моны һәр хуҗа үзе башкарырга тиеш. Тимер юлчылар поселогының күп урамнарына тимер-томыр калдыклары ташлана. Аларны 61 нче мәктәп укучылары ярдәме белән җыю үткәрелсә, урам да чистарыр, файда да булыр иде.

Депутат буларак быелның апрель аенда миңа район үзәк больницасы поликлиникасы һәм стационары эше белән танышырга туры килде. Халыкка медицина хезмәте күрсәтүдә кимчелекләр юк түгел әле, ләкин район Советы президиумы утырышында бу тикшерүгә йомгак ясаганда, тармак эшендәге уңай якларны да күрсәтеп үттем. Мисал өчен һәр кабинет ишегенә «Бөек Ватан сугышы ветераннарына чиратсыз хезмәт күрсәтелә» дигән табличкалар язылган. Сәүдә системасында элеге язуга әһәмият бирмиләр әле. Докторлар эшли торган кабинетлар чиста, теш куйдыруда чират юк диярлек. Стационарда сугыш ветераннары өчен суыткычы, самовары һәм башка кирәк-яраклары булган махсус палата оештырылган. Ветераннарга сәламәтлеген торгызу өчен бөтен шартлар бар.

Медиклар авыруларга игътибарлы. Алар үз пациентларын игътибар белән тыңлыйлар, хәлдән килгәнчә булышлык күрсәтәләр. З. А. Шабаев җитәкләгән больница коллективы мактау сүзләренә лаек, минемчә.

Депутатлар һәм сайлаучыларның эшкә бергәләп алынуы, көндәлек тормышыбыздагы җитешсезлекләрне бетерүдә уңай нәтиҗәләр бирер.

**И. ПЕТРОВ,**
район Советы депутаты, сугыш һәм хезмәт ветераннарының район советы рәисе.



«Комбайн» колхозының товарлыклы-сөтчелек фермасында соңгы елларда аренда ысулы белән эшләүгә зур әһәмият бирелә.

Әле кайчан гына Зәйтүнә һәм Әфтах Сәхипгәрәевләр мөгезле эре терлекләр симертү буенча арендада эшли башлаганнар иде. Хәзер инде моңа өченче ел китте. Алар үз карамакларындагы 1 яшькә кадәр булган 107 баш бозауның һәрберсеннән агымдагы елның алты аенда 542 грамм уртача тәүлеклек үсеш алдылар. Ә менә Илсур Сафин, Әмир Шәрапов, Фәнис Нуруллин аренда звеносында беренче елларын гына хезмәт куялар әле. Шулай булса да, Совет Армиясе сафларында чыныгу үткән бу егетләр сынатмыйча, тырышып эшлиләр. Алар 97 баш каплатылган таналардан 604 әр грамм тәүлеклек арт«е». алдылар.

Комбайнлылар аренданы әнә шулай хезмәттәге уңышлар белән раслыйлар.

Рәсемдә: аренда звеносы члennарының берсе Зәйтүнә Кирамовна Сәхипгәрәеваны күрәсез.

*• Хат юлга чакырды*

# Сездә нинди хәлләр бар?..

**Газетабызның 20 июль санында басылган «Сыйфат начар» дигән (авторы К. Измайлова) язмада Кизләү икмәк пекарнясы пешергән ипинең бик начар сыйфатлы булуы хакында сөйләнгән иде. Санитар врач ярдәмчесе Ф. Хәсәншина, Норлат икмәк заводы технологы Ә. Исмәгыйлева һәм газета корреспонденты К. Җамалетдинова хәлне урынга барып тикшерделәр.**

Пекарня үзе ипи пешерүгә яраклаштырып көйләнгән иске бинага урнашкан. Шуңа күрә бу хәлендә иң гади таләпләргә дә җавап биреп бетерер дәрәҗәдә түгел. Ипине пешерү дә, әзер продукцияне озату да, эшләүчеләрнең чәй эчү урыны да шушы бер үк зур бүлмәдә башкарыла. Барлык ихтыяҗлар өчен дә су шул ук бүлмәдәге бер краннан килә. Кул юу өчен аерым юынгыч кына да юк хәтта. Беренче килеп кергән мәлгә үзебезне узган гасырга кайткандай хис иттек. Аннан-моннан гына сугып ясалган аркылы аяклы иске өстәл.. (Өстендәге клеенкасы да үзе белән яшьтәш булса кирәк). Өстәл өстендә кадимилеге кычкырып торган тәлинкәле үлчәү. Аның тәлинкәләре һәм герләре дә археологик казылма кебек пычракка каткан—җирдән чыкканга охшаган. (Ипи пешерелә торган табалар һәм башка җиһазлар да шапшаклык ягыннан алардан калышмыйлар иде). Рейдчылар элеге иске үлчәүне тарихи экспонатның берәр серен белергә теләгәндәй җентекләп-җентекләп карасалар да, үлчәүнең бер генә җирендә дә нинди дә булса тамга-мазар күренмәде—аны файдалануга чыгарганнан бирле бер дә дөресләмәгәннәр, көйләмәгәннәр, күрәсең. Нәтиҗәдә, Кизләү пекарнясыннан 24 июльдә анализга алынган 1 нче һәм 2 нче сортлы икмәкнең авырлыгы нормадагыдан кимрәк иде.

Онны иләү өчен тиешле эрелектәге иләк кенә дә юк монда. Чүпрә саклау өчен суыткыч эшләми. «Аны төзәтәчәкләренә әле өмет тә юк»,—диделәр эшләүче кызлар. Шуңа күрә җебегән чүпрә сасы ис чыгарып, әчеп утыра. (Шулай дәвам итсә, чүпрәдә тере җан ияләре барлыкка килүе дә озак эш түгел).

Безнең халык ризыктан гаеп тапканны яратмый. Әмма Кизләү ипие безне гафу итсен, аның тәме дә, кыяфәте дә авызда су китерүдән ерак тора әле. Лаборатор анализ да шуны ук раслады: бу көнге әзер продукция әчелеге һәм дымлылыгы ягыннан нормадан ерак иде. Ипекәйнең эче хәтта чиләнеп тора. «Бу нилектән шулай соң? Сыйфатны яхшырту өчен нишләргә кирәк?»—дип без юлдашыбыз —технолог Ә. Исмәгыйлевага мөрәҗәгать иттек, шушы пекарня шартларында үтәп булырдай иң гади киңәшләр бирүен сорадык.

—Беренчедән, онны иләү өчен уртача эрелектәге иләк булдырыгыз. Ә икенчедән, сыек чүпрә әзерләү технологиясен бозасыз. Шуңа күрә ипиегез уңмый,—диде ул кызларга, аларның эш процессын җентекләп сорашкач. Аннан соң чүпрә әзерләү тәртибен аңлатты, кызларның эшендәге кимчелекләрне атап күрсәтте.—Чүпрә ясау—яшь баланы карау кебек нечкә эш ул. Чөнки чүпрә тере бактерияләрдән тора. Шуңа күрә аның белән бик сак, рәтен белеп эш итәргә кирәк,—диде Ә. Исмәгыйлева яшьләргә.

Коллективның кулыннан килердәй эшләр дә бар, әлбәттә. Әйтик, гасыр тузаны утырган пәрәвезле тәрәзәләрне бераз сөртергә, ачык өлгеләргә чебен-черки кермәслек челтәр тартырга, өстәл клеенкасын алыштырырга, берәр кулъюгычны алып урнаштырырга, ярыкларында таракан йөгерешкән иске чатан өстәлне алыштыруны сорарга мөмкиндер, ләбаса? Иләк табуы да илкүләм проблема түгел инде. Үлчәү хакында да шуны әйтергә була. Түшәмдәге чебен чуарлап бетергән шәрә (плафонсыз) лампочкалар менә-менә шартлар да алар турындагы казаннарга—камыр өстенә коелыр кебек. Ә суыткыч мәсьәләсе белән югары оешмаларның үзәгенә үтәргә кирәк—еламаган балага нәрсә диләр әле?..

Дөрес, кызлар үз көчләре белән пекарняны быел агартып чыккан идек диләр. Әмма аның булган сыйфаты да гомуми күңелсез күренешкә күмелеп кала: стеналар һәм түшәм яргаланган, тәрәзә рамнары черегән—кагылырга куркыныч..

Пекарня коллективында соңгы елларда бер генә үзгәреш булган: июнь ахырында пенсиягә киткән мөдир урынына бер яшь кызны билгеләгәннәр. Моңа кадәр мөстәкыйль эшләргә бер дә туры килмәгән бу кыз бала үзе дә пекарняның моңа кадәр күпме гомер дәвам иткән, әчпошыргыч стандартка әверелгән бертөрле яшәешенә кушылып киткән. Ә аны кулыннан җитәкләп: «Сеңелем яки кызым, эшне менә шуннан башла, алай итмә, болай ит»,—дип хәер-фатиха бирүче җитәкче дә, киңәшче дә, юл күрсәтүче дә бүгенгәчә булмаган. Пекарняның эш кәгазьләрендә дә аның ни рәвешле көн итүе белән кызыксынучыларның имзалары күренми. Санэпидстанция вәкилләреннән башкаларны күздә тотуым. (Ә соңгылары монда 1990 елның маенда һәм декабрендә, 1991 елның маенда булып үз тәкъдимнәрен, кисәтүләрен язып киткәннәр).

Халыкка антисанитария шартларында хәзерләнә торган сыйфатсыз икмәк җитештерелүен һәм аның сәбәпләрен пекарняны үз карамагында тотучы райпо (һәм азык комбинаты) җитәкчелеге беләме икән? Әллә алар еллар буена да монда аяк басмыйча, искә төшкәндә популяр халык көенә болай дип җырлыйлар микән:

Кизләү буенда—Чирмешән,
Чирмешәндә таллар бар...
Талда—яфрак, бездә—
план,
Сездә нинди хәлләр бар?..



1 кг болгар борычы, 1 кг помидор, 1 кг башлы суган, 1 кг кишер, 600 г петрушка, 600 г укроп аласың. Барысы да бик ваклап турала, шуңа 1 кг тоз кушыла. Банкаларны пластмасса капкач белән ябарга кирәк. Кыш көне борщ яки башка төрле аш пешергәндә шулпаны тозламагыз ,аңа тәмләткеч тозы да җитә.

x x x

Әгәр помидорыгыз яхшы уңыш бирсә, аны кышка күбрәк әзерләп куегыз. Помидорны ит тарткыч аша чыгарып (кабыгы белән бергә), кастрюльдә—кайнатырга кирәк. Шундый 1 литр помидорга тутырып 1 стакан тоз салалар. Стерильләштерелгән банкаларга тутырып, капкач белән борып куялар. Помидорны тозлаганда аңа маринад яки тозлык түгел, ә шушылай ит тарткычтан чыгарылган помидорны салырга киңәш итәбез. Аны хәтта кыяр яки гөмбә өстенә дә салырга мөмкин.

x x x

Кечкенә кабакны (кабачки) чистартып, эре угычта уарга ( кубиклар формасында кисәргә дә мөмкин. Өстенә борыч, ваклап туралган укроп, петрушка сибегез.

Кечкенә кабакны кыздырырга, фарш ясарга, яшелчә рагуына өстәп ашарга, духовкада пешерергә дә мөмкин.

Кабачкиның ашы да бик тәмле була. Аны ваклап турап, аз гына күләмле суга саласың, тозлыйсың. Пешкән кабакны саркытып, вак иләк аша уып чыгарыгыз. Бер аш кашыгы онны үсемлек маенда изеп, шуңа кабак пешкән суны кушыгыз. Иләктән уып чыгарылган кабакка 3/4 стакан сөт кушыгыз, ут өстенә куеп кайнатып алыгыз. Шуннан соң туглап күпертелгән йомырка салыгыз. Аны лимон согы һәм ваклап туралган укроп сибеп ашыйлар.

*Яшәү мәгънәсе турында уйланулардан*

# Иртәгә кем чираты?

Көн дә берәр яман хәбәр ишетергә туры килә: кемдер суга батып үлгән, кемнедер машина бәреп киткән, кайдадыр исерек ир хатынын тәрәзәдән ыргыткан, эчкече улы әтисен буган, талаганнар, көчләгәннәр, ватканнар, урлаганнар...Йа хода! Тагынниләр генә ишетергә насыйп икән инде дисең. Ә аннан соң болар әкренләп чигенә, көндәлек мәшәкатьләр белән тәмам онытылып та куя. Менә шулай яшибез без. Ә шушы хәлләрнең асылы, сәбәпләре хакында иркенләп уйланганыгыз бармы сезнең? Ә уйлансаң—көн дә ишетелеп торган бәхетсезлек очракларының күпчелеген булдырмый калырга да мөмкин икәнлеген аңлап хәйран каласың.

Ике кыз баланың Кондырчага батып вафат булуы турындагы хәбәр бөтен шәһәрне тетрәтте. Бу елганың яманаты шәһәрдә яшәүчеләргә күптән мәгълүм. Кемнәрнең генә күз яшьләре түгелүгә сәбәпче булмады инде ул. Әмма без әле һаман сабак ала белмибез. Эссе көннәрдә Кондырча ярында балачага шактый еш күренә.

Чынлыкта исә Кондырча—коену өчен яраксыз елга. Аның ярлары текә, ишелүчән, төбе—үзле балчык. Бәлага юлыгу өчен саксыз бер хәрәкәт тә җитә. Шул хакта һәммәбез дә белеп торабыз. Әмма ел саен бу елга бездән корбаннар ала.

Моның төп сәбәпләреннән берсе—ата-аналарның карап җиткермәве. Әлбәттә, баланы яратырга кирәк. Әмма яратуның чиге булырга тиеш. Сукырларча ярату һәрвакыт зыян гына китерә. Балага нинди дә булса рөхсәт бирәсең икән, бу шулай ук бәла белән янәшә торучы чик булырга тиеш түгел. Һәр нәрсәдә дә чама кирәк. Чаманы узуга—фаҗига тууы көн кебек ачык. Менә бер генә мисал. Көн туды исә шәһәрдә транспорт хәрәкәте башлана. Йөк төягән һәм төямәгән машиналар, тракторлар, мотоцикллар берберсен узып ашыгалар. Шунда ук мопед яки мотоцикл «иярләгән» үсмерләр тузан туздырып узып китә. Алар олы юлда гына йөреп калмыйлар, җәяүлеләр генә йөри торган, нәниләр уйный торган тын урамнарның да котын алып җилдереп узалар. Аларның баш югалтыр дәрәҗәдә ашкынып узганын күргәндә мин ирексездән: «Бу Үлем үзе йөрмиме икән шулай корбаннар эзләп?»—дип шиккә калам. «Ничек туктатырга икән аны бу саташкан «сәяхәтеннән»? Әлбәттә, авыр эш бу. Әмма мөмкин эш. Барыннан бигрәк, кирәкле эш! Ләкин ничек итеп?

ГАИ хезмәткәрләре — шикәр заводы һәм тимер юлчылар поселокларында сирәк «кунаклар». Әчкән килеш зур тизлек белән чабарга яратучылар менә шуннан бик оста файдаланалар да. Бу уңайдан, ата-аналарга да бер соравым бар: алар үзләренең балигъ булмаган балаларына мопед һәм хәтта мотоцикл сатып алып биргәндә, моның максаты хакында уйлыйлармы икән? Чынлап та, бик кирәкле ихтыяҗмы бу? Шәһәр урамнары буйлап уйсыз-нисез аркылыга-буйга чаптырып йөрсен дә үзенә дә, башкаларга да авария куркынычы тудырсын дип алулары түгелдер, ләбаса?

Үз балаңа үзең куркыныч шартлар тудыру өчен нинди рәхимсез булырга кирәктер, минемчә. Әти-әниләр исә киресенчә уйлыйлар бугай.

Шәһәрнең ГАИ хезмәткәрләре предприятие һәм оешмаларда, бигрәк тә мәктәпләрдә профилактик әңгәмәләр ешрак үткәрсәләр, мәгънәсез үлем очраклары турында тәфсилләп аңлатсалар, бер дә артык булмас иде бу.

Әлбәттә, монда безнең—янәшәдәге, әйләнә-тирәдәге кешеләрнең гаебе зур. Битарафлык күрсәтәбез, вакытында эндәшмибез, туктатмыйбыз, бәладан саклап кала белмибез. «Минем эшем түгел», дип үзебезне юатабыз. Чөнки безгә шулай тынычрак. Әмма бәла бөтен кешегә берьюлы, бер вакытта килми бит ул. Аның иртәгә кемгә киләсен бүгенгә беребез дә белми әле.

**В. ПОСЕЛЕННОВ.**
Норлат шәһәре.

# Гомуми кайгыртучанлык

Ничә еллар инде җәй җитте исә Кондырча елгасы безнең газиз балаларыбызны, оныкларыбызны, олыларны ала. Саный китсәң, йөзләгән гомер өзелгәндер шунда. Ләкин үз башына төшмәгән кеше аны белми дә, санамый да. Ә, кирәк иде.

Әлеге бәхетсезлектән ничек котылырга соң? Моңа чик куярга күптән вакыт инде. Бу беренче чиратта ОСВОДка, яшьләр оешмасына—ВЛКСМга кагыла. Ә бит шәһәрдә ОСВОД буенча һәр эшләүчедән взнос җыялар. Әнә шушы взноска елганың уңайлы урынында пляж җиһазларга мөмкин түгелме икән?! Моңа әлләни зур суммалар да кирәк түгелдер, минемчә.


Аннан соң, коену сезонында өлкән класс укучыларыннан, шулай ук ял көннәрендә предприятие, оешма, яшьләрнең дежур торуын оештыру начар булмас иде.

Шәһәр кешеләре, бигрәк тә кечкенә балалары, оныклары булганнары, минем тәкъдимемә кушылырлар, дип уйлыйм. Бу мәсьәләгә вак-төяк эш итеп карамасак, үз күз алдыбызда килгән буын һәлак булмас иде.

**И. ЕРЕПОВ.**
Норлат шәһәре.

## Объектив елмая

**Нью-Йорк ковбое...**



(ТАСС фотохроникасы).

## *Котлыйбыз!*

Зирекле авылында яшәүче кадерле әтиебез Касыйм Миннеәхмәт улы ӘХМӘТҖАНОВны туган көне белән кайнар котлыйбыз. Аңа нык сәламәтлек, шат көннәр, ак бәхетләр телибез.
**УЛЫ, КЫЗЛАРЫ, КИЯҮЛӘРЕ, ОНЫКЛАРЫ.**

# Телевидение

**ШИМБӘ**
**10 АВГУСТ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

17.05 «Бергәләп өйрәник».
17.30 «Матвеевның шатлыгы». Нәфис фильм.
19.00 «Татарстан».
19.30 «Туган җир моңнары». Телефильм-концерт (Уфа шәһәре).
19.55 «Әлли-бәлли-бәү».
20.05 «Капка төбе». Күңел ачу программасы.
20.55 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

6.30 Р. Таҗетдинов (балалайка) уйный. Казаннан тапшыру.
6.50 Документаль фильмнар.
7.30 Ритмлы гимнастика.
8.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
8.30 «ТЯХ».
8.45 А. Н. Островский. «Котырган акчалар». Фильм-спектакль.
11.15 «Иртәнге йолдыз».
12.15 Мультфильмнар.
12.55 «А курсы».
13.10 «Экология. Җәмгыять. Кеше».
13.40 Режиссер М. Захаров фильмнары. «Гадәти могҗиза». 1 нче серия.
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Җир—уртак йортыбыз». Фотоконкурс.
16.30 М. Булгаков турында хатирәләр.
17.35 Мультфильм.
18.00 «Халыкара панорама».
18.45 «Сугыш шулай башланды». Телеочерк.
19.00 «Эфирда—музыка».
19.30 «Тынлык тавышы». Нәфис фильм.
21.00 «Вакыт».
21.40 Өлкәннәр өчен мультфильм.
22.00 «Ялта-91». Конкурс һәм гала-концертның ябылуы.

**II ПРОГРАММА**

8.00 Иртәнге гимнастика.
8.15 «Сәламәтлек».
8.45 Мультфильм.
8.55 «НЛО: игълан ителмәгән визит». 14 нче тапшыру.
9.30 «Дуслык» видеоканалы.
12.00 «Плюс унбер». Видеоканал.
14.00 «Спорт һәркем өчен».
14.15 Режиссер Ю. Беспалов фильмнары.
15.10 Телеспектакль премьерасы.
21.40 «Колумбиядәге «маскалар».
22.05 «Толстой һәм Толстойлар». 2 нче тапшыру.
23.00 «Хәбәрләр».
23.15 «Кайту». Нәфис фильм. 2 нче серия.

**ЯКШӘМБЕ**
**11 АВГУСТ**
**КАЗАН КҮРСӘТӘ**

18.05 Мультфильм.
18.25 Реклама.
18.30 «Минем хәрби ресчетым». Нәфис фильм.
20.05 «Әлли-бәлли-бәү».
20.15 «Тыныч йокы, нәниләр».
20.30 Авыл хезмәтчәннәре өчен концерт.
20.55 Тапшырулар программасы.

**I ПРОГРАММА**

8.00 Ритмлы гимнастика.
8.30 «ТЯХ».
8.45 «Спортлото» тиражы.
9.00 «Иртә таңнан».
10.00 «Ватанга хезмәттә».
11.00 Иртәнге күңел ачу программасы.
11.30 Сәяхәтчеләр клубы.
13.00 Документаль фильм премьерасы.
13.15 «Якшәмбе коктейле». Музыкаль программа.
14.45 «Язмышым минем—чик буе».
15.00 «ТЯХ».
15.15 «Музыкаль киоск».
15.45 «Марафон-15».
17.00 «Авазлар күп—дөнья бер».
17.05 «Авыл сәгате».
18.05 «Шигърият минутлары».
18.10 «Уолт Дисней тәкъдим итә...»
19.00 Мультфильм премьерасы.
19.25 «Бер-берсе өчен яратылганнар». Нәфис фильм. (АКШ).
21.00 «Вакыт».
21.40 «Футбол күзәтү».
22.10 «Афәрин».

**II ПРОГРАММА**

8.00 «Зарядкага басыгыз!»
8.20 Мультфильмнар.
9.00 Документаль фильмнар.
9.30 «Дуслык» видеоканалы.
12.00 Фил Донахью программасы. «Элеккеге боксчылар-профессионаллар».
12.50 Елена Образцованың кино портретына эскизлар.
13.40 Телефильм.
14.00 Балалар өчен фильм.
15.05 Документаль фильм.
16.25 А. Глазунов. «Раймонда» балеты музыкасыннан сюиталар.
17.30 «Изгелек һәм мәңгелек».
21.40 «Коллаж».
21.45 Телеспектакль.
22.40 Лирик концерт.
23.00 «Хәбәрләр».

Мөхәррир урынбасары **Р. З. АЙЗАТУЛЛИН.**

Учредительләр халык депутатларының Октябрь район Советы, КПССның партия оешмасы.
Газетада язмалары басылган авторларның фикерләре бу әле редакция фикере дигән сүз түгел.

РЕДАКЦИЯНЕҢ АДРЕСЫ: 423000, Норлат шәһәре, К. Маркс урамы, 19.
ТЕЛЕФОННАР: мөхәррир—2—12—14, 2—22—81, мөхәррир урынбасары—2—10—44, рус теленә һәм чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир урынбасарлары—2—15—63, социаль-экономика бүлеге— 2—22—51, җаваплы секретарь—2—14—16, хатлар бүлеге һәм бухгалтерия—2—18—67.

Газетаны Фидания ХӘЙРЕТДИНОВА җыйды. Римма ГАНИЕВА верстка ясады. Клара БОБКОВА басты. Корректор Зөлфия ВӘЛИЕВА.

«Дуслык» газетасы атнаның сишәмбе, пәнҗешәмбе, шимбә көннәрендә чыга һәм рус, чуваш телләренә тәрҗемә ителә.
Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе буенча ТССР Дәүләт комитетының Октябрьның 50 еллыгы исемендәге Норлат-Октябрь типографиясе.
Күләме—1 басма табак. Заказ 95. Тираж 3415.